ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ХУҖӘМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№1 **18.09.2019 ел**

Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131_ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Татарстан Республикасы референдумы турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге уставының 11 статьясы нигезендә , Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге депутатлары җыелышы КАРАР ЧЫГАРА:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"Сез 2020 елда Хуҗәмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан; Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карар ТР, Минзәлә районы, Хуҗәмәт авылы, Мирная ур., 72 й. адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмати стендларда игълан ителергә тиеш.

Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы: Вилданова Г.Г.